Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының егерме икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 май, 2022 ел № 161

«2021-2023 елларга Питрәч муниципаль районында туризмны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру барышы турында

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары «2021-2023 елларга Питрәч муниципаль районында туризмны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматны тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Питрәч муниципаль районында 2021-2023 елларга туризмны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Мәдәни һәм тарихи мирасны саклау һәм үстерү, шулай ук социаль-икътисадый үсешкә ярдәм итә торган конкурентлыкка сәләтле туристлык индустриясен булдыру өчен туризмны комплекслы үстерү максатларында Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына киңәш итәргә:

2.1. Туристлык эшчәнлеге субъектлары тарафыннан рөхсәт документларын алу процедурасын гадиләштерүгә һәм тизләтүгә ярдәм итәргә.

2.2. түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- туристлык тармагының мәгълүмати-реклама җәлеп итүчәнлеге, Питрәч муниципаль районы имиджын туристлар үзәге буларак формалаштыру;

- Питрәч муниципаль районында туристлык объектлары турында мәгълүматлаштыруны арттыру.

2.3. «Вперед» («Алга») газетасы битләрендә һәм «Интернет» челтәрендә Программа чараларын тормышка ашыруны яктыртырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов